КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 июль г.Казань № 900

Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә «Казан триатлоны 2023» триатлон буенча спорт ярышларын уздырганда су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә «Казан триатлоны 2023» триатлон буенча спорт ярышларын уздырганда кешеләрнең тормыш куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ :

1. Кремль дамбасыннан алып Казан шәһәрендәге «Миллениум» күперенә кадәр 2023 елның 11 августында 09.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр һәм 2023 елның 12 августында 04.30 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр аз үлчәмле судноларны, шулай ук җилкәнле, йөреп кайту, спорт судноларын, гидроциклларны, байдаркаларны, ишкәкле көймәләрне дә кертеп, куллануны тыю (алга таба - тыю) билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

тыюны үтәү максатларында күрсәтелгән участокларда көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итәргә;

тыю турында халыкка хәбәр итү эшен оештырырга, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша да.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Тыю «Казан триатлоны 2023» триатлоны буенча спорт ярышларын әзерләү һәм уздыру өчен җәлеп ителгән судноларга кагылмый дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча спорт ярышларын уздырганда су объектларыннан файдалану турында» 2023 ел, 23 июнь, 742 нче;

«Зеленодольск муниципаль районы акваториясендә «SVIYAGA FEST – 2023» гаилә фестивален уздырганда су объектларыннан файдалану турында» 2023 ел, 30 июнь, 772 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин